**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№280**
**19.01.2024**

Яр Чаллы шәһәренең «11 нче спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган массакүләм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәткә тарифны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктчасы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы Карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы Карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «11 нче спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган массакүләм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәткә тарифны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «11 нче Олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2018 елның 4 декабрендәге 7243 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 19 гыйнварындагы
280 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «11 нче спорт мәктәбе»
муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе
тарафыннан күрсәтелә торган хезмәткә
тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе (сум) |
|---|---|---|---|
| 1. | Массакүләм спорт чаралары оештыру һәм үткәрү | сум/сәгать | 1800,00 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева